## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
«Бутлеровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең
Балахчино авыл торак пунктында
2024 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

**2023 елның 30 октябреннән** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Бутлеровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Балахчино авыл торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2024 елда Алексеевск муниципаль районының « Бутлеровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге Балахчино авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- кышкы һәм җәйге чорда юлларны карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

- торак пунктта урамнарны яктыртуны карап тоту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

-Комсомольская урамы буенча торак пункт юлларын төзекләндерү (юлларга таш җәю , килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

- каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен контейнер мәйданчыгы урнаштыру (төзелеш материалы алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта Бутлеровка авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә рөхсәт бирергә.

3.Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Бутлеровка авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:// alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Бутлеровка авыл җирлеге башлыгы** **И.Л. Хушанова**